# ТУГАН ТЕЛ ҺӘМ МИЛЛӘТ ЯЗМЫШЫ

**Фәһимә Миргали кызы Хисамова,**
Казан федераль университеты,
Россия, 420008, Казан, Кремль ур., 18,
hifami@yandex.ru

Мәкаләдә төрки телләр һәм татар әдәби теле үсешендә мөһим урын биләгән үзенчәлекле тарихи этаплар билгеләнә. Автор бу өлкәгә караган фәнни мәктәпләр һәм алар белән бәйле галимнәрнең эшчәнлеген ачуга да игътибар бирә. Татар теле тарихына мөнәсәбәттә исә, борынгы төрки дәвер, Алтын Урда чоры һәм Казан ханлыгы этабы үсеш эзлеклелеген саклаган хәлдә, телебез яңарышының җитди үзенчәлекләре яктыртыла. Биредә татар тел белеменең яңа дәвер казанышларыннан саналган өч томлык академик грамматика, күпсанлы фундаменталь лексикографик хезмәтләр, диалектология өлкәсендә зур әһәмияткә ия булган «Татар сөйләшләренең диалектологик атласы» турында сүз алып барыла.

**Төп төшенчәләр:** Борынгы төрки нигез тел, реконструкция, тарихи грамматика, диалектологик атлас, фәнни мәктәпләр.

## 1. Без – зур халык

Минем туган телем – татар теле – Европа һәм Азия кыйтгаларының киң мәйданнарында зур-зур этник төркемнәр булып оешкан, таралып яшәгән күп миллионлы татар халкының газизләрдән газиз туган теле, татар милләте теле ул!

Татарстан Республикасы исә – Русия киңлекләрендә яшәгән күпсанлы милләттәшләребезнең генә түгел, дөньяга сибелгән барлык татар халкының да милли-мәдәни мәркәзе.

Татар халкының географик таралышы, яшәеш ареалы, тел вәзгыяте турындагы төгәл мәгълүматларны безгә диалектолог галимнәребез генә бирә ала. Бәхеткә, диалектология фәне татар тел белемендә, шулай ук тюркологиядә дә, иң алга киткән, бай һәм нәтиҗәле эшли торган тармак булып санала. Аның чишмә башында Л.Җәләй, Л.Т.Мәхмүтова, Д.Г.Тумашева, Н.Б.Борһанова һ.б. кебек күренекле галимнәребез торды. Әлеге остазларыбызның дәвамчылары булган диалектолог галимнәребез Д.Б.Рамазанова, Ф.С.Баязитова, Ф.Ю.Юсупов һ.б., зур тырышлык куеп, киң географик мәйданда таралган күпсанлы диалект һәм сөйләшләрне тиешле фәнни югарылыкта өйрәнүгә зур өлеш керттеләр. Шул уңайдан озак еллар дәвамында башкарылган һәм 2008 елда ук инде басып чыгару өчен әзер булган «Татар сөйләшләренең диалектологик атласы» дигән өч томлык капиталь хезмәтне беркадәр шәрехләп үтәсем килә.

«Атласның....»ның тулыландырылган яңа варианты Русия территориясендә таралган барлык татар сөйләшләрен махсус программа нигезендә җентекләп тикшерү нәтиҗәләрен үз эченә ала. Яңа төзелгән «Атласка...» элеккеге вариантлар белән чагыштырганда Иделнең түбән агымында һәм Төньяк Кавказда таралыш алган әстерхан, волгоград, ставрополь татар халык сөйләшләре һәм себер татарлары сөйләшләреннән өстәмә рәвештә төмән, омск, новосибирск, кемерово сөйләшләре кертелгән. Кыскасы, Атласның яңа вариантында илебез территориясендәге татар теленең диалекталь сөйләшләре тулы һәм бөтен нечкәлекләре белән хәзерге фән таләпләре нигезендә шәрехләнгән, иң әһәмиятлесе, тарихта теркәлгән! Шуны да истә тоту мөһим: тел ул  халыкның төп билгесе һәм кадерләп сакланырга тиешле иң зур байлыгы. Бу җәһәттән әлеге капиталь хезмәт Татарстан һәм Башкортостанда таралган татар сөйләшләреннән тыш, көнчыгышта – Кемерово, көнбатышта – Рязань өлкәләреннән башлап, көньякта – Иделнең түбән агымында һәм Төньяк Кавказда таралган барлык сөйләшләрнең бер типта булуын, ягъни аларның барысының да татар теленең диалекталь вариантлары икәнлеген ышанычлы фәнни юл белән дәлилләп күрсәтә. Русиянең Ерак Көнчыгышыннан Европа уртасына кадәр таралып утырган милләттәшләребезне шул рәвешле тел буенча идентификацияләү, бербөтен халык икәнлеген дәлилләү, һичшиксез, бик зур фәнни һәм мәдәни казаныш.

Шул ук вакытта «Атлас…» – иң беренче чиратта, югары кимәлдә эшләнгән фәнни хезмәт. Аның татар тел белеме өчен әһәмияте, биредә тупланган һәм шәрехләнгән тел

материаллары татар теленең формалашу тарихын тел төзелеше буенча, ягъни структур яктан яктырту өчен, һәм тарихи грамматиканы төзү өчен дә, кыйммәтле чыганак булуы билгеле.

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: милләтне органик бербөтенгә туплауның тагын бер мөһим факторы – милли үзаңның көчле булуы. Безнең халкыбызда ул һәрвакыт сакланып килгән. Әйтергә кирәк, XX йөз башыннан алып XXI йөз барышында, тарихи-иҗтимагый вәзгыятьнең үзгәрүенә бәйле рәвештә, бездә милли үзаң аеруча көчәеп китте. Соңгы елларда бу юнәлештә Бөтендөнья татар конгрессы алып барган эшчәнлек тә зур роль уйнады. Бу уңайдан аның тарафыннан даими рәвештә оештырыла торган конгрессларга алда санап үтелгән төбәкләрдән, шулай ук дөньяның барлык почмакларыннан оешкан төстә татар халкы вәкилләре килү шул турыда сөйли.

**2. Телебез тарихына кыскача сәяхәт**

Тел белеме фәнендә тарихи аспект, ягъни телләр тарихын өйрәнү гаять әһәмиятле, шул ук вакытта шактый катлаулы, турыдан-туры халык тарихы белән бәйле өлкә булып санала. Телләр тарихын өйрәнүнең фәндә, билгеле булганча, төп ике юнәлеше бар: әдәби тел тарихы һәм тарихи грамматика.

Әдәби тел тарихы билгеле бер телдә, күбрәк якын кардәшлектә булган телләр төркемендә, язма традициянең барлыкка килүен, гасырлар дәвамында аның үсеш-үзгәрешләрен өйрәнә. Төп чыганаклар ролен бу очракта һәртөрле язма истәлекләр уйный.

Тарихи грамматика исә аерым бер телдәге, яисә кардәш телләр төркемендәге ерак гасырлардан килгән тарихи үзгәрешләрне тел төзелеше буенча, ягъни структур яктан анализлый.

Әйтергә кирәк, тюркология фәнендә һәр бу ике юнәлеш соңгы берничә гасыр дәвамында Русия галимнәренең генә түгел, чит ил алтаист галимнәренең дә игътибарын җәлеп иткән мөһим фәнни проблема булып торды.

Тюркология фәнендә әдәби телләр тарихы әле узган гасырларда ук В.В.Радлов, Ф.Е.Корш, П.М.Мелиоранский, А.Н.Самойлович, А.К.Боровков, А.Н.Кононов, С.Н.Иванов кебек галимнәрнең хезмәтләрендә яктыртылды. Икенче, соңгырак этапта әлеге өлкәгә, хосусан татар теленә кагылышлы рәвештә, зур өлеш керткән галимнәрдән, Ә.Н.Нәҗип, Э.Р.Тенишев, В.Х.Хаков, Ф.С.Хәкимҗанов, Ф.С.Фасеев, Р.Г.Әхмәтьянов, И.Б.Бәширова, Ф.Ш.Нуриева һ.б. исемнәрен атап китәргә мөмкин.

Хосусан татар язма әдәби теле тарихын өйрәнүгә килгәндә, шуны билгеләп үтү мөһим: татар теле, төрки телләр яссылыгында алганда, төрек, әзербайҗан, үзбәк, уйгыр, төрекмән телләре белән беррәттән, борынгыдан язма мәдәнияте булган телләрдән санала. XIX йөз ахыры – XX йөз башларында формалашкан татар милли әдәби теленең элгәресе булган һәм тамырлары белән иң борынгы төрки язма әдәби телләргә барып тоташкан борынгы татар язма әдәби теле шулай ук безнең милли-мәдәни мирасыбыз. Әгәр без милли әдәби телебезнең гамәлгә керүен һәм үсешен йөз елдан артык дип билгеләсәк, борынгы әдәби телнең, шулай ук тагын да борынгырак гомумтөрки язма әдәби телләрнең тарихы мең еллар белән исәпләнә.

Иске татар әдәби теленең хронологик чикләрен билгеләүгә килгәндә исә, әле соңгы вакытларга кадәр диярлек тел белемендә ике төрле караш яшәп килде. Региональ әдәби телнең югары чиген безгә татар халкы этнос буларак формалашкан чордан, XV-XVI йөзләрдән, ягъни Казан ханлыгы дәвереннән алыргамы, яки татар язма әдәби теленең чишмә башы XIII-XIV йөзләрдән – Алтын Урда чорыннан ук киләме? Әйтергә кирәк, бу ике караш та фәнни яктан нигезсез түгел.

Иске, ягъни классик әдәби телләрнең башлангычы бик борынгыдан килү сәбәпле, үткәнгә киткән саен, элеккеге мирас үзара кардәш халыкларның уртак милке, уртак мәдәни казанышы санала. Төрки халыкларның әдәби-язма мирасының чишмә башы Орхон-Енисей ташъязмалары (V-VI гасыр) һәм борынгы уйгыр язма ядкәрләреннән соң (IX-X гасыр), Урта Азия регионында формалашкан төрки язма әдәби тел – караханилар дәвере әдәби теле, карахани-уйгыр әдәби теле (X-XII гасыр) була. Шуңа күрә әдәби телләр тарихы турында сүз барганда, без еш кына Урта Азия әдәби теле истәлекләре дигән гыйбарә белән очрашабыз.

Бу чордагы әдәби телдән, билгеле булганча, Йосыф Баласагунлының «Котадгу белек» дидактик поэмасы (XI гасыр), Әхмәд Ясәви хикмәтләре (XII йөз башы), Сөләйман Бакыргани әсәрләре (XII гасыр) һ.б. сакланып калган.

Берничә гасыр дәвамында (XIII-XIV) күпсанлы җәүһәрләр биргән Алтын Урда чоры

әдәби теле гомумтөрки әдәби телләр тарихының чираттагы этабы санала. Ул – кодрәтле империя теле, һәм бу әдәби телнең гаять киң регионда – Төньяк Харәзмнән алып, Идел буена чаклы, ә көньякта исә Мисырга кадәр таралышында галимнәр төп ике мәдәни үзәкне билгелиләр: *беренче үзәк*, чыннан да Урта Азия регионы белән бәйле Төньяк Харәзм һәм Сыр-дәрья елгасының түбән агымында таралган борынгы харәзм, ягъни караханиуйгыр әдәби теле. Әлеге регионда борынгы Урта Азия әдәби теле традицияләренең алга таба да тотрыклы саклануы, билгеле, табигый күренеш.

Алтын Урда дәүләтенең тарихта тирән эз калдырган *икенче* иҗтимагый-сәяси һәм мәдәни үзәге, билгеле, Идел буенда барлыкка килгән Жучи олысы (улусы), ягъни Алтын Урда дәүләте һәм Сарай шәһәре була. Бу уңайдан күренекле тюрколог, борынгы төрки язма истәлекләребезне өйрәнүгә зур өлеш керткән галим Әмир Нәҗип түбәндәгеләрне билгеләп уза: «...территория Джучеева улуса была довольно обширной, и Золотая Орда имела несколько культурных центров. Одним из культурных очагов был Северный Хорезм – низовье Сыр-Дарьи, сохраняющий еще былые традиции тюркской (караханидско-уйгурской) письменной культуры Средней Азии; другим таким же центром уже в XII-XIII вв. было низовье Волги – Сарай ... А с XIV в. появляется новый очаг – Египет ... На территории современного Египта нашел свое дальнейшее развитие золотоордынский смешанный кыпчако-огузский письменный язык» [1: 16]. Галимнең әлеге фикерендә, безнеңчә, ике момент аеруча игътибарга лаек. Беренчедән, аның раславынча, Идел буенда төрки язма әдәби телнең XII-XIII йөзләргә нисбәтләнүе, ягъни әле монгол яулап алуларына кадәр үк Түбән Идел регионында үзенчәлекле классик төрки-татар язма әдәби телнең гамәлдә йөрүе, ә икенчесе – әлеге язма әдәби телнең диалекталь нигезе, Урта Азия әдәби теленнән аермалы буларак, катнаш кыпчак-угыз (угызкыпчак) теле булуы. Бу уңайдан, мәсәлән, XIII гасыр башларында язылган «Кыйссаи Йосыф» поэмасының (Кол Гали әсәре) нәкъ шул катнаш кыпчак-угыз әдәби телендә Иделнең түбән агымында Саксин шәһәрендә язылуы тюркология фәнендә расланган хакыйкать дип санарга мөмкин [2: 7-26].

Бу очракта без, тел тарихы фәнендә билгеле булганча, милләткәчә чордагы гомуми әдәби телләрнең, төрле тарихи-иҗтимагый шартларга бәйле рәвештә, бер географик төбәктән икенче төбәккә күчеше белән очрашабыз. Әлеге күчешнең асылы борынгы традицион тел үзенчәлекләрен күпмедер дәрәҗәдә саклаган хәлдә, әдәби телнең диалекталь нигезе үзгәрү юлы белән бара.

Шул рәвешле, XIII гасыр башларында ук Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф» поэмасы белән нигезе салынган һәм XIII-XIV йөзләрдә Харәзминең «Мәхәббәтнамә», Котбның «Хөсрәү вә Ширин» поэмалары, Хисам Кятибнең «Җөмҗөмә солтан» дастаны, Сәйф Сараиның «Гөлстан бит-төрки» әсәре һ.б. кебек классик төрки-татар поэзиясенең кабатланмас гүзәл үрнәкләрен, шулай ук һәртөрле проза әсәрләрен һәм тарихи язмаларны мулдан биргән Алтын Урда чоры төрки-татар язма әдәби телен турыдан-туры татар язма әдәби теленең элгәресе, аның чишмә башы дип саный алабыз. Шул ук вакытта әлеге язма әдәби мирас гомумән төрки халыклар мәдәнияте үсешенең дә әһәмиятле этабын тәшкил иткәнлеген дә билгеләп үтәргә кирәк.

Билгеле булганча, XV йөзнең беренче яртысында һәртөрле иҗтимагый-сәяси сәбәпләр аркасында Алтын Урда дәүләте таркалганнан соң, аның биләмәләрендә, бер-бер артлы төрле татар ханлыклары: Себер ханлыгы (20 нче еллар), Казан ханлыгы (30 нчы еллар), Кырым ханлыгы (40 нчы еллар) һ.б. барлыкка килә [3: 75].

Казан ханлыгы чорын (XV-XVI йөзләр) галимнәр, хаклы рәвештә болгар һәм кыпчак кабилә телләренең кушылуы нигезендә бердәм татар халык сөйләмә теленең формалашу чоры дип саныйлар [4: 19; 5: 120]. Моның ышанычлы дәлилләрен без, мәсәлән, Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдъяр әсәрләрендә (XVI йөз), шулай ук Казан ханлыгы чоры поэзиясенең дәвамчысы булган Мәүлә Колый шигырьләрендә (XVII йөз) һ.б. күрә алабыз:

*Кем қулыңдин килгәничә қыйл яхшылық,*
*Сәңа бер көн тәқый килгәй яхшылық*
*Сән яхшылық қыйл, яхшылыкта бар мәза,*[1]
*Кем яманлығ қыйлса, ул тапқай җәза...*

(Мөхәммәдъяр).

*Йаз көнендә болыты аз чуақ ула*
*Йегет кеше қайгусы йуқ даим көлә,*
*Қарый кеше мисле һаман қыш тик була,*
*Шул сыйфатлы ғомре кәчәр қөдрәт берлә....*

(Мәүлә Колый)

[1] Мәза – файда

XVI йөз уртасында Казан ханлыгы һәм башка татар ханлыклары Рус дәүләте тарафыннан яулап алынганнан соң барлыкка килгән иҗтимагый-мәдәни һәм сәяси вәзгыятьне билгеләп, тарихчы галимнәр аның гомумән татар халкы язмышына гына түгел, ә мәдәният, әдәбият һәм язма әдәби тел үсешенә дә тирән йогынты ясавын билгелиләр: «...со второй половины XVI в. до начала XX в., когда литературный язык, лишенный постоянно унифицирующего форму, стимулизирующего развитие центра, каким является феодальное государство, развивался слишком анархично, поддаваясь каждому дуновению внешнего ветра... Следовательно, стиле-языковая пестрота, смешанность татарского литературного языка есть исторический продукт конкретных условий....» [3: 67].

Галим бу очракта бик хаклы, чөнки әле XIV-XV гасырларда ук югары үсеш дәрәҗәсенә ирешкән, XVI йөздә Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдъяр иҗаты белән беркетелгән татар язма әдәби теленең соңгырак этапта, ягъни XVIII-XIX йөзләрдә кулланылышы буенча яки Урта Азия әдәби теленә тартымлыгын, XIX гасырда исә төрек әдәби теле тәэсирендә булуын, төрек теле тәэсиренең өстенлек ала башлавын, ягъни әлеге «тел-стиль чуарлыкларының» сәбәбен бик дөрес күрсәтеп бирә.

Бу чорда югарыда китерелгән классик поэзия үрнәкләреннән тыш, «Кәлилә вә Димнә» (XIV-XV гасыр). «Мәҗмугыль хикәят» кебек тәрҗемә характерындагы проза әсәрләре, Кадыйр Гали бәкнең «Җәмигъ-әт-тәварих» (XVII гасыр), Хисаметдин Мөслиминең «Тәварихы Болгария», Таҗетдин Ялчыголның «Тарихнамәи Болгар» (XIX гасыр) һ.б. кебек тарихи язмалары шактый киң кулланылышта була [3; 6-8]. Әмма мәдәниятебез үсеше өчен шактый катлаулы, «торгынлык» дип атарга мөмкин булган шушы чорда да язма әдәби телнең үзенчәлекле бер функциональ тармагы булган рәсми эш кәгазьләре стиле көнчыгыш дәүләтләр белән халыкара аралашу теле сыйфатында, XIII-XIV йөзләрдәге Алтын Урда ярлыкларыннан башлап, XIX йөз урталарына кадәр һәрдаим актив кулланылышта була.

Бу очракта без татар язма әдәби теленең өч гасырдан артык дәвердә, (XVI-XIX йөзләр) Россия империясенең Көнчыгыш илләр белән дипломатия бәйләнешләрендә икенче дәүләт теле вазифасында кулланылуын күздә тотабыз. Татар әдәби теле тарихы өчен зур әһәмияткә ия булган әлеге күренешкә телчеләрнең игътибарын юнәлтүдә беренче чиратта тарихчы галимнәребез Миркасыйм Госманов һәм Сәлам Алишевларның роле зур булды. Әдәби тел тарихы контекстында әлеге феноменны өйрәнү исә, алдарак искәртелгәнчә, татар теленең күп гасырлар дәвамында Россиядә икенче дәүләт теле вазифасында кулланылышын тулысынча расларга мөмкинлек бирде [9]. Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: татар теле тарихына кагылышлы әлеге күренеш узган гасыр башларында ук тарихи аспектта рус галимнәре тарафыннан да шактый гына дәрәҗәдә шәрехләнгән була. Мәсәлән, В.В.Бартольд рус дипломатик миссияләрендә эшләгән татарлар турында түбәндәгечә яза: «Это представители тех служилых татар (казанских, касимовских, астраханских), которые в XVII-XVIII вв. оказали России большие услуги при сношениях с переднеазиатскими и даже восточноазиатскими государствами. Благодаря находившимся на русской службе татарам, русское правительство для сношений с правительствами мусульманских стран располагало готовыми кадрами переводчиков» [10: 182].

Татар тәрҗемәчеләре төрле канцелярияләрдә хатларны тәрҗемә итеп кенә калмаганнар, ә илчелек составында үзләре дә төрле илләргә барып, экспертлар сыйфатында алар белән дипломатия эшләрен башкаруда турыдан-туры катнашканнар. Бу турыда беркадәр негатив рухта булса да, тарихчы В.В.Григорьев түбәндәгеләрне яза: «Эти господа, как магометане, не могли быть искренне преданы Русскому правительству, им было не по душе, что кяфиры русские наказывали собратий их, магометан-кайсаков, хотя и за дело. Вот эти переводчики, через которых велись все сношения с кайсаками, которые во всех совещаниях администрации участвовали как эксперты, без которых ничего не предпринималось, ничего не делалось...» [11: 23].

Тарихчы галимнәрнең хезмәтләрендә шулай ук әлеге чорларда илчелектә, ягъни Посол приказында эшләгән татар тәрҗемәчеләре турында да кызыклы мәгълүматлар бар, аларның кайберләренең исемнәре дә теркәлеп калган. Мәсәлән, тарихчы С.А.Белокуров 1689 елда Мәскәүдә Посол приказында эшләгән татар кешеләренең исемнәрен китерә[2]: Кучукай Сакаев, Сулейман Тонкачиев, Петр Татаринов, Резеп Байцын, Тохтаралей Багинин, Билял Безиргинов, Кодралей... [12: 31].

[2] Исемнәр русча язылышта китерелә

Тел тарихы фәненең икенче юнәлеше булган тарихи грамматикада гомумхалык сөйләмә теле тарихы төзелеше буенча, ягъни структур яктан өйрәнелә.

Мәгълүм булганча, татар теле үзенең тамырлары белән бик ерак чорларга, иң борынгы төрки нигез телгә барып тоташа, һәм телебезнең тарихи грамматикасын өйрәнү дә гомуми рәвештә төрки телләрнең чагыштырмалы-тарихи грамматикасын өйрәнү контекстында бара һәм күпмедер дәрәҗәдә аның состав өлешен тәшкил итә.

Татар теленең тарихи грамматикасын өйрәнүгә багышланган махсус хезмәтләр чагыштырмача соң, узган гасырның урталарына таба гына мәйданга чыга башлый. Бу уңайдан, иң элек күренекле диалектолог һәм тел тарихчысы Латыйф ага Җәләй хезмәтләрен искә алырга кирәк. Галимнең 1954 елда чыккан «Татар теленең тарихи фонетикасы буенча материаллар» дигән хезмәтендә татар телендәге сузык һәм тартык авазлар тарихы шактый эзлекле яктыртыла һәм андагы күп кенә фикерләр бүгенге тел тарихы фәне өчен дә әһәмиятен югалтмый. Л.Җәләйнең икенче капиталь хезмәте телебезнең грамматик төзелешен (морфологиясен) тарихи юнәлештә өйрәнүгә багышланган. Профессор Л.Җәләйнең университет студентларына тел тарихыннан укыган лекцияләренең кульязмалары нигезендә төзелгән, бу китап 2000 нче елда басылып чыкты [13]. Китапны басмага күренекле тел галимнәре Ф.С.Фасеев һәм Ф.Ю.Юсупов һ.б. әзерләделәр.

Татар теленең тарихи грамматикасын өйрәнүгә нигез салган икенче бер әһәмиятле хезмәт – Казан лингвистика мәктәбенең күренекле вәкиле, Казан дәүләт университеты профессоры, русист галим В.А.Богородицкийның «Введение в татарское языкознание» дигән хезмәте [14]. Аның мөхәррире зур тюрколог-галим Н.К.Дмитриев була. В.А.Богородицкийның бу хезмәте татар теленең тарихи грамматикасы буенча беренче гаять җитди хезмәт булу белән бергә, ул, гомумән, төрки телләрнең чагыштырмалы – тарихи грамматикасын өйрәнүгә дә зур өлеш кертә, анда, мәсәлән, төрки телләрдәге тартыклар һәм сузыклар системасын чагыштырып өйрәнү, Идел буендагы төрки телләрдә сузыклар күчеше, төрки телләрдәге монгол телләре белән фонетик уртаклыклар һ.б. мәсьәләләр гаять җитди фәнни югарылыкта анализлана.

Татар теленең тарихи грамматикасын өйрәнү җәһәтеннән бу хезмәттә «Фонетика» бүлеге аеруча әһәмиятле. Телебезнең вокализмын (сузыкларын) һәм консонантизмын (тартык авазлар системасын) чагыштырмалы рәвештә өйрәнүгә багышланган бу бүлектә авазлар башта сыйфатлары, ягъни ясалыш, әйтелеш үзенчәлекләре ягыннан рус теле авазлары белән чагыштырыла, һәр ике телдәге авазларның типологик юнәлештә уртак һәм үзенчәлекле яклары ачыклана. Галим, мәсәлән, рус һәм татар телләрендә бары тик ике сузык авазның, ягъни *и* һәм *у* авазларының гына төп билгеләр буенча охшаш булуларын, шул ук вакытта *а* авазының, иренләшү төсмереннән тыш, арттарак ясалуын (...имеет более глубокую артикуляцию), *о, ө* авазларының бик кыска әйтелешен һәм күтәрелеш буенча (по подъему) рус телендәге *ō* авазыннан таррак булуын, һ.б. билгеләр. Шунысы әһәмиятле: галим бу нәтиҗәләрен эксперименталь ысуллар белән дә дәлилли.

Галим, үз хезмәтенең икенче өлешен исә турыдан-туры татар теле авазларын тарихи юнәлештә өйрәнүгә багышлый, татар теле авазлары төрки телләрдән төрек, алтай, казах, чуаш телләре белән, шулай ук монгол телләре белән чагыштырыла.

Төрки телләр тарихының гомумтюркология фәне күләмендә өйрәнелү дәрәҗәсенә килгәндә исә, әле узган гасырның икенче яртыларыннан башлап соңгы вакытларга кадәр диярлек дәвердә Мәскәү һәм Ленинград (хәзерге Санкт-Петербург) галимнәренең бу өлкәдәге күләмле һәм зур фәнни кыйммәткә ия булган эш нәтиҗәләрен билгеләп үтәргә кирәк. Россия тюркология фәнендә әлеге чорда төрки телләрне чагыштырмалы-тарихи ысул белән өйрәнү өлкәсендә хезмәт куйган һәм бай фәнни мирас калдырган галим, ул, һичшиксез, тюркологиянең Ленинград мәктәбе вәкиле А.М.Щербак. 1970 елда аның төрки телләрнең чагыштырмалы-тарихи фонетикасы буенча күләмле хезмәте басылып чыга [15]. Дөнья тюркология фәне казанышларына таянып һәм аларны фәнни-тәнкыйди юнәлештә тәфсилле анализлап язылган бу хезмәт бер үк вакытта бөтен төрки телләр материалларына нигезләнгән булуы белән дә гаять зур фәнни-методик әһәмияткә ия.

Төрки телләр тарихын эзлекле өйрәнүне дәвам итеп, галим 1977-1987 елларда чагыштырмалы-тарихи морфология буенча өч томлык хезмәтен бастыра [16-18].

Төрки телләр тарихын, аларның тарихи грамматикасын өйрәнүнең яңа этабы Мәскәү тюркологлары тарафыннан олуг тюрколог-галим, академик, безнең хөрмәтле милләттәшебез Әдһәм Рәхим улы Тенишев җитәкчелегендә төрки телләрнең чагыштырмалы-тарихи грамматикасы буенча күптомлы гаять зур фәнни кыйммәткә ия булган коллектив хезмәт язылуы белән характерлана. Әлеге хезмәтнең беренче дүрт томы төрки телләрнең төзелеше буенча төрле тармакларын (фонетика, морфология, синтаксис, лексикология) чагыштырмалы-тарихи ысул белән өйрәнүгә һәм шулар нигезендә иң борынгы төрки нигез телне (тюркский праязык) реконструкцияләүгә багышланган [19-22]. Региональ реконструкцияләргә багышланган бишенче том төрки телләрнең төрле этник төркемнәрен (угыз, кыпчак, карлук-уйгур һ.б.) һәм аларның нигез телләрен реконструкцияләүне үз эченә ала [23]. Алтынчы, йомгаклау томында исә алдагы томнардагы мәгълүматлар гомумиләштерелә. Бу томның икенче бүлеге лексика материаллары нигезендә борынгы төркиләрнең дөнья картиналарын өйрәнүгә багышлана [24].

Шуны да билгеләп үтәргә кирәк: хәзерге заман лингвистика фәне югарылыгында эшләнгән әлеге капиталь хезмәтләрнең чыгуы төрки телләр тарихын гомуми планда өйрәнү өчен генә түгел, ә аерым төрки телләрнең грамматик төзелешенә хас кайбер мәсьәләләрне дә яңача фәнни нигездә аңлатырга мөмкинлек бирә.

Традицион тюркология фәнендә, мәсәлән, кыпчак төркеменә кергән телләр, шул исәптән татар теле дә, тарихи яктан күп кенә структур үзгәрешләр кичергән «яңа» телләрдән санала иде. Борынгы һәм иң борынгы төрки нигез телне яңача фәнни нигездә реконструкцияләү нәтиҗәләре күп кенә очракларда татар теленең борынгы нигез телгә шактый якын торуын дәлилләргә дә мөмкинлек бирә. Төгәлрәк якын килсәк, татар телендәге типологик яктан да иң борынгы сүз төркемнәреннән саналган зат алмашлыклары, шулай ук берәмлек сан атамалары үзләренең борынгы төрки телдәге архетипларына бик якын торалар. Мәсәлән, *мин* <*män, *mēn, *минем* <*вinim, *pinim, *мине* <*вini, *pini, *миңа* <*вina,*pina һ.б.

Аерым төрки телләрдә исә зат алмашлыклары һәм аларның кыек килештәге вариантлары күптөрле үзгәреш кичергән яңгыраштa килә: *mağa, sağa* (миңа, сиңа), *mağan, sağan, manin, sanin* (минем, синең) һ.б.

Берәмлек сан исемнәреннән татар телендәге *бер, ике, өч* һ.б. сан исемнәре түбәндәгечә реконструкцияләнә: *бер* - * bi:r < * pi:r; *ике* iki – ike – äki; *өч* *üč- öč һ.б.

### 3. Телебез саклауга һәм яклауга мохтаҗ

Телебез тарихын өйрәнү проблемаларыннан бүгенгегә күчсәк, татар теле фәне өлкәсендәге элекке фәнни казанышларның закончалыклы дәвамы буларак, хәзерге төп фәнни үзәкләр булган Казан (Идел буе) федераль университетында һәм Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында ярты гасырдан артык дәвердә күп тармаклы һәм масштаблы фәнни тикшеренү эшләре алып барыла. Рус һәм татар телләрендә өч томда «Татар грамматикасы» төзелде (баш мөхәррире – профессор, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы М.З.Зәкиев). Академик М.З.Зәкиевнең соңгы еллардагы фәнни кызыксыну өлкәсе шулай ук, тел материалларына таянып, халык тарихын өйрәнүгә багышлана. Хөрмәтле өлкән буын галимнәребез Л.Т.Мәхмүтова һәм Д.Г.Тумашева җитәкчелегендә күпсанлы татар халык сөйләшләрен өйрәнү буенча ирешелгән нәтиҗәләр турында без инде алдан ук искәрткән идек. Әлеге елларда шулай ук өлкән буын галимнәребез иҗтиһаты белән татар теле фәнендә күп кенә яңа юнәлешләр барлыкка килде. Шундыйлардан татар лексикография фәнендә күпсанлы фундаменталь хезмәтләр авторы, үзенең фәнни мәктәбен булдырган галим, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы, профессор Ф.Ә.Ганиев, татар тел белемендә ономастика фәненә нигез салган, күпсанлы яшь галимнәр тәрбияләгән профессор Г.Ф.Саттаров һәм аның җитәкчелегендә фәнгә аяк баскан, ономастиканың бер тармагы булган гидронимия өлкәсендә әле бүген дә актив эшли торган күренекле галим, профессор Ф.Г.Гарипова, тел культурасы өлкәсендә күп фәнни хезмәтләр авторы, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе академигы Р.А.Юсуповларның хезмәтләрен аерым билгеләп үтәргә кирәк.

Билгеле булганча, фән дәвамчанлыкны ярата. Хәзерге татар тел белеме фәнендә өлкән буын галимнәребезнең эшен дәвам итүче, шул ук вакытта хәзерге тел белеме фәнендәге өр-яңа

тармакларны үзләштереп, саллы фәнни хезмәтләрен дөньяга чыгарган чираттагы буын Р.Р.Җамалетдинов, Ф.Ш.Нуриева, Ә.Ш.Юсупова, Г.Р.Галиуллина, А.Ә.Тимерханов, Г.К.Һадиева һ.б. кебек дәрәҗәле галимнәребез үзләре инде яшь фәнни кадрлар хәзерләү белән бергә, гомумән, татар теле фәнен оештыру, үстерү өлкәсендә дә актив эшчәнлек алып баралар.

Тел фәне, тел өйрәнү өлкәсендәге казанышларыбыз турында шундый оптимистик рухта сүз алып бара алсак та, телебезне саклау һәм яклау өлкәсендә шактый гына хәвефле яклар булуны танырга туры килә.

Шәһәр җирләрендәге актив икетеллелек, авыллар язмышы һәм аларга бәйле рәвештә милли мәктәпләрнең кими баруы кебек объектив сәбәпләрдән тыш, биредә Үзәктән Русиядәге милли телләргә карата тулысынча битараф һәртөрле карарларның килә торуы һ.б. телебезнең киләчәк язмышына карата борчылу тудырмый калмый, билгеле. Әмма минем бу язмамда бәян ителгәнчә, без – зур халык, бик борынгы язма мәдәниятkә ия булган, күп миллионлы, көчле рухлы халык. Без телебезне югалтмабыз!

**Әдәбият**


1. *Наджип Э.Н.* Тюркоязычный памятник XIV века «Гулистан» Сейфа Сараи и его язык. Алма-Ата, 1975. 210 с.
2. *Хисамов Н.Ш.* Кол Гали һәм аның «Кыйсса-и Йосыф» дастаны. Казан: Татар. кит. нәшр., 2012. 285 б.
3. *Усманов М.А.* Татарские исторические источники XVII-XVIII вв. Казань, 1972. 221 с.
4. *Хакимзянов Ф.С.* О Поволжском варианте среднетюркского языка // Историко-лингвистический анализ старописьменных памятников. Казань, 1983. С.3-25
5. *Закиев М.З.* «Кыйсаии Йусуф» Кул Гали и этноязыковая ситуация в Волжской Булгарии // Поэт-гуманист Кул Гали. Казань, 1987. 262 с.
6. *Галяутдинов И.Г.* «Тарих наме-и булгар» Таджетдина Ялсыгулова: автореф. канд. дис. М., 1977. 25 с.
7. *Рәхим Г., Газиз Г.* Татар әдәбияты тарихы. Беренче җилд. Борынгы дәвер. Казан, 1924 316 с.
8. *Хисамиева З.А.* Язык дастанов Кадыр-Гали бека. Автореф. канд. дис. Уфа, 1981. 21 с.
9. *Хисамова Ф.М.* Татарский язык в восточной дипломатии России. Казань: Татар. кн. изд-во, 2012. 402 с.
10. *Бартольд В.* История изучения Востока в Европе и России. Ленинград, 1925. 318 с.
11. *Григорьев В.В.* Письма из зауральской степи. М., 1862. 145 с.
12. *Белокуров С.А.* О посольском приказе. М., 1906. 170 с.
13. *Җәләй Л.* Татар теленең тарихи морфологиясе (очерклар). Казан: «Фикер», 2000. 286 б.
14. *Богородицкий В.А.* Введение в татарское языкознание. Казань, 1953. 220 с.
15. *Щербак А.М.* Сравнительная фонетика тюркских языков. Л.: Наука, 1970. 202 с.
16. *Щербак А.М.* Очерки по сравнительной морфологии тюркских языков (имя). Л., 1977. 193 с.
17. *Щербак А.М.* Очерки по сравнительной морфологии тюркских языков (глагол). Л., 1981.181 с.
18. *Щербак А.М.* Очерки по сравнительной морфологии тюркских языков (Наречие, служебные части речи, изобразительные слова). Л.: Наука, (Ленинградское отделение), 1987. 149 с.
19. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Фонетика. М.: Наука, 1984. 488 с.
20. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Морфология. М.: Наука, 1988. 557 с.
21. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Синтаксис. М.: Наука, 1986. 435 с.
22. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Лексика. М.: 2001. 822 с.
23. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Региональные конструкции. М.: Наука, 2002. 767 с.
24. Сравнительно-историческая грамматика тюркских языков. Пратюркский язык-основа. Картина мира. М.: Наука, 2006. 907 с.